# КАРАР

**Татарстан РеспубликасыТүбән Кама муниципаль районы Кармалы авыл җирлеге составына керүче Кармалы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

2019 елның 7 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2019 елның 7 ноябрендә уздырылган «Түбән Кама муниципаль районының Кармалы авыл җирлеге Кармалы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча белеем алучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә 2020 елда үзара салым кертү белән килешәсезме. Әлеге сумманың 50% ы күләмендә 2 төркем инвалидлар түли. Һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү:

- Кармалы авылында Ленин һәм Яр буе урамнарында янгын гидрантларын урнаштыру;
- Карамалы авылындагы поселок эчендәге юлларны төзекләндерү

ӘЙЕ ЮК».

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 459 җыенда катнашучы граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашќан җыенда катнашучы гражданнар саны 264 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 262 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 2 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кармалы авыл җирлеге составына керүче Кармалы торак пунктында гражданнар җыенын булган дип, халык җыены нәтиҗәләрен чын дип таныырга.

2.«Түбән Кама муниципаль районының Кармалы авыл җирлеге Кармалы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы

буенча белем алучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә 2020 елда үзара салым кертү белән килешәсезме. Әлеге сумманың 50% ы күләмендә 2 төркем инвалидлар түли. Һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү:

- Кармалы авылында Ленин һәм Яр буе урамнарында янгын гидрантларын урнаштыру;
- Карамалы авылындагы поселок эчендәге юлларны төзекләндерү

ӘЙЕ ЮК».

мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Кармалы авыл җирлеге сайтында һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4.Әлегекарарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кармалы авыл җирлеге башлыгы А.Д. Кубышкин